ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ
**КАРАРЫ**

«Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» Татарстан Республикасы Законының 16 һәм 17 статьяларына үзгәрешләр кертү хакында» 38-7 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты турында

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы депутаты А.Г. Хәбибуллин тарафыннан кертелгән «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» Татарстан Республикасы Законының 16 һәм 17 статьяларына үзгәрешләр кертү хакында» 38-7 номерлы Татарстан Республикасы законы проектын беренче укылышта кабул итәргә.

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы Рәисе Ф.Х. Мөхәммәтшин

БЕРКЕТМӘ БҮЛЕГЕ
ПРОТОКОЛЬНЫЙ ОТДЕЛ

Казан шәһәре,
2025 елның 20 феврале
№ 192-VII ДС

Проект
Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы депутаты
А.Г. Хәбибуллин
тарафыннан кертелә

**«Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» Татарстан Республикасы Законының 16 һәм 17 статьяларына үзгәрешләр кертү хакында**

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЗАКОНЫ

**1 статья**

«Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2004, № 7 (II өлеш); 2005, № 2, № 4 (I өлеш), № 6 (II өлеш), № 11; 2006, № 4, № 7 (I өлеш); 2007, № 7 (I өлеш), № 8; 2008, № 1; 2009, № 1, № 12 (I өлеш); 2010, № 7 (II өлеш), № 12 (II өлеш); 2011, № 3, № 11 (I өлеш); 2012, № 7 (I өлеш), № 11 (I өлеш); 2013, № 3, № 7, № 12 (I өлеш); 2014, № 5, № 11 (VI өлеш); 2015, № 7 (I өлеш), № 11 (I өлеш); 2016, № 3, № 5, № 6 (I өлеш), № 9 (II өлеш); Татарстан Республикасы законнар җыелмасы, 2017, № 1 (I өлеш), № 27 (I өлеш), № 55 (I өлеш), № 76 (I өлеш); 2018, № 1 (I өлеш), № 22 (I өлеш), № 54 (I өлеш), № 78 (I өлеш), № 92 (I өлеш); 2019, № 19 (I өлеш); 2020, № 1 (I өлеш), № 4 (I өлеш), № 37 (I өлеш), № 57 (I өлеш), № 77 (I өлеш); 2021, № 1 (I өлеш), № 29 (I өлеш), № 36 (I өлеш), № 57 (I өлеш), № 77 (I өлеш), № 93 (I өлеш); 2022, № 17 (I өлеш), № 24 (I өлеш); 2023, № 3 (I өлеш), № 27 (I өлеш), № 73 (I өлеш), № 81 (I өлеш), № 92 (I өлеш), № 96 (I өлеш); 2024, № 18 (I өлеш), № 47 (I өлеш), № 56 (I өлеш), № 76 (I өлеш), № 79 (I өлеш); Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталы (PRAVO.TATARSTAN.RU), 2024 елның 12 декабре) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 16 статьяның 1 өлешендәге 11 пунктында «белем бирүдән тыш) оештыру» сүзләреннән соң «, муниципаль мәгариф оешмаларында өстәмә спорт әзерлеге уку-укыту программалары буенча өлкәннәргә өстәмә белем бирүне оештыру» сүзләрен өстәргә;

2) 17 статьяның 1 өлешендәге 13 пунктында «белем бирүдән тыш) оештыру» сүзләреннән соң «, муниципаль мәгариф оешмаларында өстәмә спорт әзерлеге уку-укыту программалары буенча өлкәннәргә өстәмә белем бирүне оештыру» сүзләрен өстәргә.

**2 статья**

1. Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

2. «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 16 статьясындагы 1 өлешенең 11 пункты, 17 статьясындагы 1 өлешенең 13 пункты нигезләмәләре (әлеге Закон редакциясендә) 2023 елның 1 гыйнварыннан барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла.

Татарстан Республикасы
Рәисе

**«Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» Татарстан Республикасы Законының 16 һәм 17 статьяларына үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы законы проектына аңлатма**

Закон проекты «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законын федераль законнардагы үзгәрешләргә туры китерүгә юнәлдерелгән.

«Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 2024 елның 13 декабрендәге 471-ФЗ номерлы Федераль закон белән муниципаль районнарның һәм шәһәр округларының җирле әһәмияттәге мәсьәләләренә муниципаль мәгариф оешмаларында өстәмә спорт әзерлеге уку-укыту программалары буенча өлкәннәргә өстәмә белем бирүне оештыру мәсьәләсе кертелде.

Әлеге нигезләмәләрнең гамәлдә булуы 2023 елның 1 гыйнварыннан барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла (чөнки «Россия Федерациясендә физик культура һәм спорт турында» Федераль законга һәм «Россия Федерациясендә мәгариф турында» Федераль законга үзгәрешләр кертү турында» 2021 елның 30 апрелендәге 127-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә өстәмә спорт әзерлеге уку-укыту программалары өстәмә гомуми белем бирү программаларының бер төре буларак кертелде).

Бәян ителгәннәргә бәйле рәвештә, закон проекты белән «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү карала.

**«Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» Татарстан Республикасы Законының 16 һәм 17 статьяларына үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы законын кабул итүгә бәйле рәвештә үз көчләрен югалткан дип танылырга, туктатылып торырга, үзгәрешләр кертелергә яисә кабул ителергә тиешле Татарстан Республикасы законнары һәм башка норматив хокукый актлары**

**ИСЕМЛЕГЕ**

«Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» Татарстан Республикасы Законының 16 һәм 17 статьяларына үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы законын кабул итү Татарстан Республикасы законнарын һәм башка норматив хокукый актларын үз көчләрен югалткан дип тануны, туктатып торуны, үзгәрешләр кертүне яисә кабул итүне таләп итми.

**«Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» Татарстан Республикасы Законының 16 һәм 17 статьяларына үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы законы проектын**
**ФИНАНС-ИКЪТИСАДЫЙ НИГЕЗЛӘҮ**

«Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» Татарстан Республикасы Законының 16 һәм 17 статьяларына статьяларына үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы законын кабул итү Татарстан Республикасы бюджетыннан өстәмә акчалар бүлеп бирүне таләп итми.